**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 октябрь № 775

г. Казань

Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турында нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы составын раслау хакында

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 10 өлеш һәм 2016 ел, 5 сентябрь, С-577-АЦ/Д14 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләр бирү турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы составы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 24 октябрь, 775 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен төшенчәләр һәм терминнар «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.2. Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы (алга таба – эксперт советы) коллегиаль орган булып тора һәм даими нигездә эш итә.

## 2. Эксперт советы вәкаләтләре

2.1. Федераль закон нигезендә эксперт советы:

а) Федераль законның 13 статьясындагы 9 өлеш нигезендә махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга теләк белдергән затлар тапшырган бизнес-планнарны бәяләүне гамәлгә ашыра һәм бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре буенча бизнес-планга булышу турында яки бизнес-планга булышудан баш тарту хакында карар кабул итә (Федераль законның 13 статьясындагы 6 өлешнең 2 пунктында күздә тотылган очраклардан тыш);

б) Федераль законның 13 статьясындагы 12 өлеш нигезендә бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яки берничә йөкләмәне үтәүне махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга теләк белдергән һәм Федераль законда билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявка биргән затка йөкләү турында карар кабул итә;

в) махсус икътисадый зона резидентының бизнес-план үзгәрү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү шартлары үзгәрү хакында гариза белән мөрәҗәгате нигезендә Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеш нигезендә бизнес-планга булышу турында яки бизнес-планга булышудан баш тарту хакында, шулай ук Федераль законның 18 статьясындагы 5 өлеш нигезендә бизнес-планга үзгәреш кертү буенча бер яки берничә йөкләмәне үтәүне мондый резидентка йөкләү турында карар кабул итә.

## 3. Эксперт советы составы һәм аның эшен оештыру

3.1. Эксперт советы составына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, кредит-финанс оешмалары, фәнни һәм бүтән оешмалар вәкилләре керә ала.

3.2. Эксперт советы эксперт советы рәисе, эксперт советының җаваплы секретаре һәм эксперт советы әгъзаларыннан гыйбарәт. Эксперт советы әгъзаларының гомуми саны 13 кеше тәшкил итәргә тиеш.

3.3. Эксперт советы рәисе эксперт советы әгъзалары арасыннан, эксперт советы әгъзалары утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән сайлана. Эксперт советы теләсә кайсы вакытта вакытыннан алда эксперт советы рәисе вәкаләтләрен туктатырга хокуклы.

3.4. Эксперт советының җаваплы секретаре эксперт советы әгъзалары тарафыннан эксперт советы әгъзалары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкилләре арасыннан яки Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның идарә компаниясе хезмәткәрләре арасыннан чикләнмәгән вакытка сайлап куела.

3.5. Эксперт советы карарлары зарур булган саен үткәрелә торган утырышларда эксперт советы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда эксперт советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

Эксперт советының һәрбер әгъзасы эксперт советы утырышында яки язмача рәвештә аерым фикерен белдерергә хокуклы, ул эксперт советы утырышы беркетмәсендә чагылыш таба.

Эксперт советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга эксперт советы рәисе һәм эксперт советының җаваплы секретаре имза куя.

Эксперт советы карарлары Федераль законда билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрелә.

3.6. Эксперт советының эш регламентын эксперт советы утырышта раслый һәм Федераль законда эксперт советы карарларын җибәрү өчен каралган вакытларда, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кергән көннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру максатында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрелә.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 24 октябрь, 775 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонаның эксперт советы**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Автушенко Евгений Владимирович | «Махсус икътисадый зоналар» АҖнең Проектлар белән идарә итү һәм инвесторлар белән эшләү буенча департаменты директоры (килешү буенча) |
| Әхмиева Эльмира Әхтәм кызы | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Агеев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов Рөстәм Ринат улы | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» АҖнең инвесторлар белән багланышлар буенча генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Китайцева Людмила Романовна | Татарстанның Банклар ассоциациясе советы рәисе (килешү буенча) |
| Мартынов Евгений Васильевич | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Миңуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Милявский Виталий Владимирович | «Махсус икътисадый зоналар» АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Мостафин Харис Вәгыйз улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Субботина Ирина Петровна | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм архитектура сәясәте бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Хаҗиәхмәтов Булат Зөфәр улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |
| Хөсаенов Алмаз Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Феоктистов Андрей Анатольевич | «АК БАРС» БАНК ГАҖнең Корпоратив бизнес департаменты директоры (килешү буенча). |